СОВЕТ БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2025 елның 19 декабре** Бишнә ав. **№ 22**

Бишнә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 2024 елның 10 сентябрендәге 198 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 28.11.2025 ел № 425-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Бишнә авыл җирлеге Советы **карар кылды:**

1. Бишнә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 10.09.2024 ел, №198 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 6 пунктчасында түбәндәге сүзләрне өстәргә: «проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер ай узгач, әмма физик затлар мөлкәтенә салым буенча чираттагы салым (хисап) чорының 1 числосыннан да иртәрәк түгел үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Бишнә авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**